Һәр язмышның – үз ияСе, Һәр тарихның – үз гыйбрәте



И. Надиров. 1997 ел.

Мин Нәдер авылында туган меңнәрнең берсе. Балачагымда, төгәлрәге 1932-1936 елларда, шул авыл мәктәбендә укып йөрүемне, аннан соңгы чорда әти-әнием белән Ютазы районындагы Алмата дигән поселокта яшәвемне искә төшерәм. Әмма Нәдер гомерем буе хәтеремнән чыкмады. Искә алган Алматада безнең гаилә кыерсытылган хәлдә фәкыйрь генә тормыш алып барырга дучар ителгән иде. (Аның сәбәпләре хакында әти-әниемнең озын истәлекләрендә тәфсилләп язылган). Шуңа күрәдер, Нәдер һәм Тайсугандагы туганнарым мине ел саен җәйге каникул айларында үзләренә чакыралар иде. Бөек Ватан сугышы башланган кайгылы көн дә Нәдердә чагыма туры килде. Бу борынгы татар авылы минем күңелемне үзенең милли сыйфатларга бай традицион көнкүреше, йолалары, халкының ачык чырайлы булуы, табигатенең гүзәллеге белән яулап алгандыр дип уйлыйм. Нәдердән соң миңа татар халык ижатын җыючы, өйрәнүче галим буларак Татарстанда гына түгел, Русиянең күп кенә өлкәләренә таралып утырган йөзләгән татар авылларында булырга туры килде. Әмма Нәдер кебек матур, милли рухлы авыллар бармак белән генә санарлык булып истә калган. Бу сүзләр газиз туган авылыма карата ихластан әйтелгән мактау һәм ярату сүзләре булып кабул ителсен иде.

Нәдер яныннан борналанып агучы ямьле Зәй буйларында, куе урманнарда йөргәнебез, тауларга менгәнебез, «Изге чишмә» дип аталган чишмәдән тәмле су эчкәнебез, авылның тирә-якка атаклы алма бакчасында булганыбыз әкияти төш кебек әле дә хәтердә тора. Шунысы үкенечле, Нәдердә хәзер якын кардәшләребез калмады, язмыш аларны төрле тарафка таратты.

Бай тарихлы борынгы авыл булса да, Нәдер хакында әлегә хәтле махсус хезмәтләр язылмаган диярлек. Шулай да соңгы елларда дөнья күргән дүрт чыганакны аерып күрсәтер идем. Алар дүртесе дүрт жанрга карый, дүрт стильдә язылганнар, ләкин фәнни әһәмиятләре ягыннан мактап телгә алырлык кыйммәткә ияләр. Минемчә, мәгълүматка иң бае — Әлмәттә яшәүче тарихчы Рәфыйк Әмирхановның «Образование Надыровской волости и основание села Альметьево» (к проблеме заселения края)

дигән мәкаләсе[1]. Бу мәкаләдә Нәдер Үрәзмәтов (1711-1758) дигән зирәк бер кешенең Яңа Нәдер һәм аның тирәсендәге берничә авылга нигез салуы, шул чордагы патша хезмәткәрләре белән бәйләнештә торуы, «старшина» дигән рәсми исемгә лаек булуы тарихи документлар ярдәмендә дәлилләп күрсәтелә. Мәкаләдә Нәдер бабайның нәсел тамырлары турында да кызыклы гына хәбәрләр бар.

Икенче чыганак исә үзенең тарихи язмалары, әдәби әсәрләре белән танылган һәм Сарманда яшәүче галим Дамир Гарифуллинның «Җиде җил дуенында» дигән китабы. Аның тышында «Җәлил поселогы тарихы буенча кыскача хәбәрләр» дигән аңлатма да бирелгән. Китапта фәннилеге белән әйбәт тәэсир калдыра торган «Нәдер волосте һәм Нәдер Үрәзмәтов турында сүз» дип исемләнгән кечкенә бер бүлекчә бар[2]. Анда автор тарафыннан ясалган, Нәдер Үразмәтовның XVIII гасырдан башлап бүгенге көннәргә кадәр сузылган нәсел агачы (шәҗәрә) рәсемен аерым кыйммәткә ия бер сәхифә дияр идем (шәҗәрәдә әтием Нурислам ягыннан булган һәм безнең гаилә тарихын күз алдына китерә торган нәсел тамыры бирелүен рәхмәт тойгысы белән билгеләп үтим).

Өченче чыганак — ике галимнең — Раиф Мәрданов белән Ирек Һадиевның Кукмара районы газетасында басылган һәм яңа документларга байлыгы ягыннан истә калучы мәкаләсе[3].

Хуплау сүзләре белән телгә аласы килгән дүртенче чыганак — мәгълүм педагог, журналист һәм язучы Хатип Хәбибуллинның «Язмыш сукмагы» дигән китабы[4]. Нәдердә туып үскән бу автор авылга булган тирән мәхәббәтен аерым истәлек, мәкалә һәм хикәяләрендә сурәтли. Китапны яратып, сокланып укыйсың, чөнки ул Нәдернең кешеләрен, табигатен җылы хисләр, күркәм сүзләр ярдәмендә тасвирлый алган.

Нәдер авылының бай тарихына бәйле кайбер мәгълүматлар безнең гаилә архивыбызда да саклана. Алар: әтием Нурислам Шаһисламовның (1888-1964) үз кулы белән язган күләмле генә (кулъязма 34 биттән тора) тәрҗемәи хәле һәм әнием — Мәгъмүрә Шаһисламованың (1900-1987) миңа сөйләгән хатирәләре. Бу язмаларда урын алган вакыйга-хәлләр безнең хосуси гаилә тормышын гына чагылдырмый, алар узган гасырның беренче яртысындагы татар авылына хас социаль көнкүреш үзенчәлекләре хакында сөйли торган шәхси-тарихи документлар буларак та игътибарга лаек.



И. Надировның әтисе Нурислам һәм әнисе Мәгъмүрә.
Ютазы районы, Алмата авылы, 1951 ел.

ИСКӘРМӘЛӘР:
1. Проблемы изучения истории заселения и образования населенных пунктов Альметьевского региона. Материалы симпозиума. Альметьевск, 25-27 мая 2000 г. – Казань, 2000. – С. 3-15.
2. Гарифуллин Д. Җиде җил дуенында. – Яр Чаллы, 2004. – Б. 8-12.
3. Мәрданов Р., Һадиев И. Нәдер Үрәзмәтов һәм аның нәселе // Хезмәт даны. – 2003. – 6, 11 сентябрь.
4. Хәбибуллин Х. Язмыш сукмагы. – Төмән, 2002. – 255 б.

Илбарис Надиров,
филология фәннәре кандидаты

Кайгы күрми егет ир булмый
(Нурислам Шаһисламов истәлекләре)*

1959-1960 еллар.

Элеккеге Самар губерниясе, Бөгелмә өязендә Нәдер дигән бер авыл бар. Бу зур авыл Зәй елгасы буена урнашкан. Авылның бу урынга кайчан утыруы, ни өчен Нәдер дип аталуы хакында халык арасында төрле имеш-мимешләр йөри. Имеш, Екатерина II патшалык иткән дәвердә төрек иле белән сугыш барган. Хатын патша бер вакыт шул сугышта йөргәндә, аны төрекләр үтергәнче кыйнап сазлыкка ташлаганнар. Ләкин Екатерина исән калган. Аның янына урыс армиясенең ике солдаты килеп чыкканнар да, әби патшаны танып алып, коткарганнар. Патша үзен коткаручыларга бүләк бирергә булган. Солдатларның берсе — Нәдер Үрәзмәт исемле икән. Ул үзенә җир сораган. Патша аңа хәзерге Нәдер авылы урнашкан тирәдән зур гына мәйдан бирергә карар кылган. Нәдер бирегә күчеп килгәч, авылны аның исеме белән атаганнар. Аңа дворян исеме бирелгән. Җирнең чикләре Самар белән Уфага кадәр сузылган икән. Нәдер карт күп җирләрен сатып, якыннарына өләшеп бетергән. Ахырдан үзе дә җирсез калган. Бу вакытта әби патша үлгән була инде. Нәдер картка судлаша торгач сажинга-сажин үлчәп, башкалар белән тигез итеп җир бирелгән. Бөлгән дворян авылына Казан ягыннан килгән халык тулган. 800 дән артык хуҗалык җыйналган. Бу хәбәрне яшь чагында ишеткән идем.

Мин шушы авылда, 1888 елда 11 январьда Шаһислам исемле крестьян гаиләсендә туганмын. Бабаларымның исемнәрен әле дә хәтерлим — әтием Шаһисламның әтисе Ибраһим, аның әтисе Монасыйп, аның әтисе Йосыф, аның әтисе Якуп, аның әтисе Әюп, Әюпнең әтисе Нәдер... Нәдер картның әтисен белүчеләр юк.

Әтием Шаһислам карт урта хәлле крестьян булган. Ул 1855-1860 еллар тирәсендә туган. 18 яшендә приемнан (солдатка алынудан) калгач, Исхак хаҗига ялланып кучер булып эшләгән. Шунда эшләгәндә, Әлмәттә өйләнә. Әнием Сабый исемле балта остасының кызы — Зөһрә була. Миннән башка безнең семьяда тагын ике бала була — Фатыйма (1884), Мөкәррәмә (1886). Беренче апам тиздән үлеп китә.

Әтием Нәдердә 1891 елны үлә. Әнием дә бер елдан соң, авырып үлеп китә. Без Мөкәррәмә апа белән ике бала ятим калдык — миңа бер ат белән йорт туры килгән. Аннары мине әтиемнең агасы Солтан тәрбиягә алган. Мөкәррәмә апам Ильяс исемле туганнары кулында калган.

Мин 12-13 яшькә кадәр Нәдернең иске мәдрәсәсенә укырга йөрдем. 14 яшемдә Солтангәрәй байга эшкә ялландым. Елына 12 сум акча, бер пар күлмәк-ыштан, ике пар бияләй, ике кием оек, бер җилән бирергә булды. Чабатаны үзем ясап киярга тиеш идем. 15 яшькә чыккач Карабашка киттем. Анда хәзрәт үзе укыта, кара, кәгазь, каләм бирәләр икән дигән хәбәрне ишеткән идем. 30 чакрым җирне җәяүләп килеп, кич сәгать 8 дә барып керәм җизниләргә. Икенче көнне үк мине Әхмәтсәгыйть хәлфәгә илтеп, укырга бирделәр. Мәктәптә шәкертләр күп, күңелле. «Мөхтасар»ны, коръән тәфсирен яхшылап үзләштердем. Җизнәйләр бик тәрбияләп тоттылар. Бер үк вакытта җәйләрен тырма тырмалап, сарык көтеп йөрим, көзләрен-кышларын укыйм.

Җизнәй, Бөгелмәдә Исхак хаҗиның кассиры булганлыктан, шактый бай иде. Малҗир бар. Алай да мин качарга булдым. Мәдрәсәдән бөтен әйберләрне кайтарып куйдым да, бер ятим малай белән Ржаевка боярына ялланырга ниятләдек (Бөгелмә аръягында). Бу 1905-1906 елларда булды. Эшлибез. Менә бер вакыт бояр казармасына бер ничә кеше килделәр. Алар революционерлар булып чыкты. Иртәгә помещикны таларга барабыз

* Истәлекләрнең кулъязмасы И. Надиров архивында саклана. Басмада кыскартып бирелде.

диләр. Таланган малларны бүләләр. Без Җәлалетдин исемле 19 яшьлек егет белән бу хәлләрдән куркып качтык. Боярны талауны ишеткәч патша гаскәр җибәрде. Күтәрелешне бастырдылар. Мин Карабашка кайтып киттем.

Өс-баш әйбәт иде. Егет чак. 1907 елда Кодаш авылыннан килгән Тәхави бай малае үзләренә ялчылыкка чакырды. Ул үзе сәүдәгәр булып Әлмәт-Сөләй базарларында сату итеп йөри иде. Аның улы Хәниф белән без ситса сатып йөрдек. Буш вакыт аз, чөнки йорт эшендә дә катнаштым. Шундый хәлне хәтерлим: Тәхави белән Әлмәткә барабыз. Кара төн. Мукшы авылы кырында арба чокырга ауды. Бай малае комач астында басылып калды. Кычкыра бу: «Чыгар тизрәк, үләм», — ди. Мин көләм моннан: «Шулаймы, үләсеңме? Үл! Мине сүгәсең, кычкырасың. Башкача алай эшләмәсеңме? Әйт, ант ит», — дим. Ант итте бу. Бер елга якын ачуланышмый гына йөрдек. Аннан расчет алдым да, Нәдергә кайтып киттем.

Бер вакыт Әлмәтнең Йосыф бай малае Зәки үзенә батраклыкка чакырды. Ул сатучы иде. Аңа ялландым. Коры кеше. Мине авылдашлар алдында «бурлак» дип сүгә иде. Мин урысча белмәгәч, бурлакны «бур» белән бутап моңа ачуым килде. Бер чак тоттым да ачуланыштым, ул куркып чыгып качты. Кибет минем кулда калды. Аннары мин кайтып киттем. Өйгә килде, ялына бу. Ат җигеп кил, дидем. Расчет сорадым, бирмәде. Казанга барып кайт инде, аннан китәрсең, ди. Яхшы эшли идем, шуңа чыгарасы килмәде. Көйләп, чөйләп бер ел йөртте бу. Миңа 19 яшь иде инде.

Нәдергә кайттым. Арслан хаҗи Нәдернең иң атаклы алпавытларыннан берсе. Анда ике елдан артык батрак булып эшләдем, приемга кадәр. Хаҗиның 15 баш аты, 15 сыеры, 50-60 сарыгы бар иде.

Прием килеп җитте. 1910 елда Ахун бай малае Шәрифҗан, Рамазан Гыйльфаны һәм 10-15 егет җыйналдык. Шәрифҗан дус кеше иде. Солдатка бармас өчен, йомырка гына эчеп, начар ашап нечкәрде. Аны нәзек дип калдырдылар. Миңа льгота бар иде. Мөкәррәмә апаны минем тәрбиядә итеп күрсәтеп, әти-әнием юк дип калдырдылар. Мөкәррәмә апаны «Мактама башына» кияүгә бирделәр.

1911 елда мин Нәдернең бер егете Миңнехуҗа белән читкә чыгып киттем. Бәләбәйгә кадәр атка утырып бардык. Аннан Уфага киттек поезд белән. Атна чамасы грузчик булып йөрдек пристаньда. Минем паспорт та юк бит, свидетельство гына. Монда ошамады. Икәү Чиләбегә юнәлдек. 10 көнгә якын вокзалда грузчик булып йөрдек. Аннары контрактныйлар янына яшеренеп кенә утырдык та, Себергә сыпырдык. Иркутскига җиттек. Аннан пароход белән Читага. Тимер юл эшләнә торган тупикта тукталдык. Урман кисәргә тотындык. Бу юлны Коротков дигән бай эшләтә иде. Анда әллә никадәр тоннель, косогор бар иде. Безнең авыл кешеләре бар дип ишетеп, Хабаровскига киттем. Солдатлардан сораштым — берәү дә белми. Миңнехуҗа Читага китеп барды, шунда очрашырга булдык...

1914 ел якынайды. Ак билетларны сугышка ала башладылар. Мин һаман тимер юл эшчесе булып йөрим. Нәбиулла Гибанов дигән бер иптәш белән Благовещенски шәһәреннән чикне үтеп, Амурны көймәдә чыктык та Махүга юнәлдек. Кытай шәһәре, акча бар. Ике ай чамасы тордык. Спиртонос булырга исәп бар. Дүртәү булдык — ике урыс, Нәбиулла һәм мин. Монда спиртның 5 шешәсе 18 тиен көмеш, ә бездә 10 тәңкә. Кытайлар бик күп. Русча беләләр. Бер вакыт спирт җыйдык та Амур аша киттек чыгып. Сакчыларны көйләдек.

Акча күбәйде. Тагын киттек, кытайларны яллап күбрәк алып чыга башладык. Ике ел чамасы йөрдек. Соңгы чыгуда берничә көймәдә идек. Яныбызда ефәккә, йонга төрелгән 116 чиләк спирт иде. Юлдашлар 48 кытай. Көзге яфраклар коелган чак, 1915 елның көзе.

Таможнийлар белән очраштык. Алар 8 ат өстендә, коралланганнар. Сугыш булды. Чигенсәк тә, кырпак кар өстендә эзләр кала. Яшеренгән җирдән икенче көнне 20 ләп таможник чолгап алдылар, бик каты кыйнадылар. Кытайларны кайтарып җибәрделәр. Таможниклар бар да кораллы. Безнең дүртебезне алып кайттылар үз стансаларына. Коралларны, әйберләрне алдылар. Сәгатьләр, алтын балдакларда бар иде. Допрослар башланды. Безне 3 көн тоткач, Благовещенскига алып киттеләр, алар ат өстендә, без җәяү, юл буенча чыбыркы белән кыйнап бардылар. Аннары конвой астында пароход белән Хабаровскига җибәрделәр. Пристаньдә урыслар икесе дә качты, без икебез кача алма-

дык. Шәһәр төрмәсенә яптылар, 1915 елның ноябрь ае иде, революция булганчы, шунда ике ел яттык. Безгә суд булмый торды, кичектерделәр. Безгә әйтәләр: «Сезгә котылу юк, я үлем, я 20 ел төрмә», — диләр.

Революция булгач та, без яткан төрмәгә кызыллар, партизаннар килеп керде. Суд булмаганнарга тикшерү башланды, суд булганнарны я бәхилләделәр, я сугышка бару вәгъдәсе белән чыгардылар. Мин пекарь булып эшләгәнгә почет бар иде, өс-баш таланса да, ярыйсы иде.

Мине чыгарганда, юлга 18 тәңкә акча, справка, билет бирделәр. Владивостокка киттем. Танышларны табып, пристаньда — товарный дворда эшләргә калдым. Баржаларда әйбер бушатабыз, төяп озатабыз. Керенский акчаларын кочак-кочак ала идек. Пристань буенда зур сарайга озын өстәлгә күмәч, балык китерәләр иде — эшлисең, ашыйсың, туктап тору юк. Эше күп булганда, акчасы да күп керә иде. Илгә кайтасы килә иде инде үземнең дә, бер кемгә дә хат язмыйча 8-9 ел үтеп китте бит. Уйлыйм инде, кайтып җитсәм Солтан җизнигә бер 100 сум бирәм дә, кире Себер якларына чыгып китәм дип.

Кайта торгач килеп җиттек Николаевски дигән стансага. Петропавелны, Чиләбеләрне уздым. Уфага җиттек. Кассага киттем. Хәзер Бөгелмәгә кайтасы бар бит. Касса янында күрәм, бер бәләкәй малай бөтерелә минем янда. «Син, абзый, кая барасың?», — ди. «Мин Бөгелмәгә — Урсалы волостена», — дим. Шулай диюгә ул миңа: «Нурислам абый, әллә синме бу?» — ди. «Әйе, — дим. — Син кем буласың?» «Мин синең туганың, Сөләйман булам. Солтан улы», — ди. Аптырап калдым. Ул теге бәләкәй Мәсүп җиңгинең улы икән. Мин киткәндә ул җиңгинең кечкенә генә малае калган иде. Шул булып чыкты. Сораша башладым. Ул әйтә: «Мин өйдән чыгып китәргә мәҗбүр булдым. Әни үлде, әти яшь хатын алды, мине кага башладылар. Менә бер ел инде шулай йөрим», — ди. Карыйм, аягында чабата, өстендә бер алама пинҗәк, аркасында бер капчык.

Мин аны авылга бергә кайтырга өндәдем: «Бераз кунак булабыз да, кире минем белән китәрбез», — дидем. Килеште бу. Уфада аны киендердем. Өстенә костюм, аягына шиблет ботинкасы, фуражка, күлмәк-ыштан алдым. Аннары билет алып Бөгелмәгә юл тоттык. Анда кайткач, Шаһгали абзыйларга төштек. Аларда кунаклар бар иде. Безне мунчага җибәрделәр. Бу 1918 елның 28 марты иде. Өч көн буе кунак булдык монда. 1 апрельдә Шаһгали абзый Әлмәттән кәләш алып кайтты — Әшрәф кызын. Нәдернең Сәхәбие китерде тройка белән. Болар кайткач, тагын күтәренке күңел белән бер көн булдык та, Сәхәбине яллап, тройка белән Нәдергә киттек. 40 сум бирдем. Карабаштагы абыстайга кердем. Җизни үлгән икән. Шунда абыстайга 10 аршин ситса бирдем. Бик куанды, бик күп рәхмәтләр укыды. Минем исән булуыма гаҗәпләнде. Без ашыгып кына кабат юлга кузгалдык. Бер сәгатьтән Нәдергә кайтып та җиттек. Солтан абзыйлар капкасы алдында тукталдык. Тройка, дугаларда кыңгырау чылтырый. Бу хәлне күреп халык җыелды, бала-чага... Нурислам белән Сөләйман кайтканнар дигән хәбәрне тиз тараткаңнар. Минем өс-баш менә дигән, кара пальто, кара костюм, башта эшләпә, аякта ялтыравык ботинкалар, кулда көкре таяк. Янда ике чемодан. Сөләйман да яхшы кыяфәтле. Мин балаларга көмеш акча чәчтем, бусы инде дан өчен дә эшләнде.

Минем Нәдергә кайтып төшкән көн 1918 елның 3 апреле иде. Солтан абзый бик хуп күреп өйгә алып керде. Ул арада чәй дә өлгерде. Күчтәнәчләрем күп иде, күмәч, конфет, ләндерин, такта чәй — бар да өстәлгә куелды. Күрше-тирә, туган-тумачалар белән өй тулды. Чөнки 8-9 ел бер хәбәрсез хат та салмыйча йөреп кайттым бит.

Ат белән олаучы булып, йөк ташып йөри башладым. Әлмәттән Бөгелмәгә, Бөгелмәдән Богырысланга. Аннан он ташып көн итә башладым. 1919 ел килеп җитте. Җәен сабан сөреп икмәк чәчүдә булсам, кышын йөк ташыдым. Богырысланнан Чаллыга, Алабугага да йөрдек. Үз файдама берәр капчык он салып кайта идем. Егерменче ел да шул эш белән үтте.

Егерме беренче ел ачлык булды. Бу елда мине Әлмәтнең волость исполкомына военкоматка эшкә алдылар. Бер ел диярлек дезертирлар белән көрәшеп үтте. Аннары военкоматтан үзем сорап киттем. Грамотам юк, миңа мондый эш авыр дигәч җибәрделәр. Атны сатып икмәк алырга туры килде. Алай да күпмедер вакыттан кабат ат алып, йөк ташуга күчтем. Бу эш белән тагын өч ел буе шөгыльләндем. Үзебез өчен икмәк игү эшләрен эшләргә дә туры килде.

1925 елда поселкага күчмәк булып язылдык бер ничә кеше, шунда күчү нияте белән

йөрибез. Без уйлаган идек Петровка бояры урынныннан җир алырбыз дип. Тик алай булып чыкмады. Андрей Пузанов дигән бояр җиреннән бирергә булганнар. Без Җиһангиров Рамазан белән анда бармаска булсак та, Нәдер халкы безнең калуга риза булмаган диделәр... Шуннан соң без 1926 елның язында яңа урынга күченеп килдек. Бөгелмә районы, Урал авыл советы, Пузанов җиренә Алмата исеме кушылды. Андагы совхоз каядыр күчеп китте. Бу урынга без ничек күчеп килдек. Үзем 1888 елда туган, хатыным Мәгъмүрә 1900 елда туган, Илбарыс исемле бер улым бар (1925 елда туган), хатынның әнисе — әби бар, 75 яшьләрендә. Минем бер ат бар. Нәдердәге өйне сатып алдым.

Шулай итеп яңа урында бер иске өйне сипләп тора башладык.

Хөкүмәт урман биргән иде халыкка, мин дә шуның хисабына бер бура буратып куйдым. 1927 елда бер кладовой салдырдым таштан, боярның каралтысын бүлгәндә миңа да таш бирелгән иде.

Ярый, 1928 елда икмәкләр яхшы уңды. Көчкә урып җыйдык игенне. Алты кеше бер булып урак машинасы алдык. Шул машина белән бер урып карадык. Бөгелмә земотделы озын срок белән түләргә дип, бер молотилка бирде. Ул ике ел ятты чокырда, моны теләүчегә килеп суктыру өчен гомуми җыелыш белән рөхсәт бирергә булдылар. Ул вакытта молотилканы беребез дә күрмәгән бит, рәтен белмибез. Алай да Ярулла, Габдрахман белән өчебез каешлар сатып алып 4 ат җигеп суктырып карадык. «Новое поле» авылыннан бер урыс мастеры алып килгән идек. Молотилканың ничек эшләвен кararга бөтен авыл җыелды. Шулай итеп бер кышны ашлык суктык. 1929 елда колхозлашу күренә башлады. Бу вакыт мине бик байга санап, ургычы, молотилкасы бар дип, хезмәтчеләр тота дип сөйләүчеләр булган. Дөресендә, мин бер кайчан да хезмәтче тотмадым, үзем гомер буе хезмәтче булган кеше бит.

1929 елда барыбыз да колхозга кердек. Халык надан. Счетовод юк колхозда. Тоттылар да мине хисапчы итеп куйдылар. Юкса, мин дә бер нәрсә белмим бит инде. Самоучка. Русчам бар аз гына, иске хәрефләр белән татарча язгалый алам. Шул гына. Авыл советы председателе урыс — Кудряшов Михаил иде. Мин язам берәр кәгазь русча, ул бер нәрсә дә аңламыйм, дип кире җибәрә. Шуннан бер вакыт Сталин иптәшнең «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе чыга. Колхоз таралып та бетә. Шул вакыт миңа син гариза язып биргәнсең дип, юк бәла тагалар. Кудряшов бу хәбәрне ишетеп, мине бик шелтәләде. Шуннан бу юк бәланы таккач, мин дә түзмәдем, ачуым килеп колхоздан чыктым. Ярый, язга чыктык. Игеннәр чәчтек. Без бер аерым хуҗалык инде. Икмәк уңды. Мин колхозга кабат кайтырга теләп, гариза язсам да мине кабат алмадылар. Келәттәге икмәкләрне көчләп алып киттеләр. 1931 елда июнь аенда ГПУ килде. Бер нинди тикшерүсез, судсыз-нисез кулак ясадылар да куйдылар. Сабитов Хәйретдин белән икебезне атка утыртып Бөгелмәгә озаттылар. Барып кердек төрмәгә, өченче камерага, шпаналар бүлмәсенә. Халык шыгырым.

Менә шулай бетте ул колхозга керү хәле. Бәләкәй генә эштән, алдый-алдый зур эш чыгардылар. Дөреслекне тикшерүче булмады, яклаучы булмады. Оятсыз, көнче кешеләргә ышандылар, мине тыңламадылар. Шул кара эчле кешеләр аркасында Бөгелмә төрмәсенә килеп эләктем.

1931 елның августында булса кирәк, безне бу төрмәдән монастырьга күчерделәр. Бер ай чамасы шунда яттык. Шунда чагында бер көнне, көтмәгәндә, Алматадан Мәгъмүрәне, Илбарысны, әбине әйберләр белән китерделәр. Әбине икенче көнне Нәдердән Сабир бажа гариза биреп алып китте. Шул монастырь казармасында 10 көн яттык. Аннары барыбызны да вокзалга алып киттеләр. Халыкның иге-чиге юк. Кара болыт кебек. Ahваһ килеп елаучыларның тавышы кая карама ишетелеп тора. Вагоннарга төяделәр. Без: «Каласың инде Бөгелмә, каласыз туган җирләр», — дип җырлап барабыз. Бер заман барып җиттек Уржумка дигән станциягә... Төшерделәр безне. Карлы яңгыр ява. Салкын. Коридорда ятабыз. Мин чирләдем шунда. Шул төнне безнең бөтен багажны урлап киттеләр вокзал ишек алдыннан. Бөтен кием-салым, савыт-саба, урын-ятак әйберләре юкка чыкты. Ярый, иртән атлар килде. Сельхозкомбинаттан биш чакрым ерактарак икән без яшәргә тиеш урын. Ат сарайларын чистартып шунда урнаштык. Рәт-рәт сәкеләр ясадык. Мич юк. Салкын. Ашларны урамда пешерәбез. Бик тыгыз. 800 ләп кеше диделәр. Монда күбесе байлар, муллалар икән. Мин генә ярлы булганга, гарьләнәм дә, хурланам да. Мәгъмүрә дә бик ачулана. «Без монда ник килдек, ник җибәрделәр безне монда»?

— ди. Монда эшли башладык. Дранка ярабыз. Минем белән бергә Камы авылыннан Гариф Кашапов, Нуретдин Фәрхетдинов, Колшәриф авылыннан Мансур Минһаҗев белән Җиһанша мулла улы Әнәсләр эшли. Дранка белән түбәләр ябабыз.

Мәгъмүрә бит авырлы булып килгән иде. Ул 1931 елның ноябрь ахырларында бер бәби — малай тапты. Аңа Әмир дип исем куштык. Күпмедер вакыттан соң скарлатина чыгып Мәгъмүрә белән Илбарыс чирли башладылар да, аларны Златоустка илтеп больниска салдым. Бәләкәй бәби белән мин дә киттем. Алар анда бер ай чамасы яттылар. Аннары безне күчерергә хәбәр килде. Вавилово стансасына — урман кисәргә. 20 чакрым урман эченә. Бу декабрь ае иде инде. Их, салкын бозлы яңгыр ява көн-төне, шул чагында өшүләрем... Хәзер дә җылына алмаган төсле тоела. Барып кердек бер баракка, тимер миче бар, 6 семья идек. Утын кисәргә куштылар. Мине бригадир иттеләр. Ул кара урман куркыныч та иде. Аюлар, бүреләр, еланнар күп иде. Бер ел анда эшләп үтте... 1932 елның июнь аенда хатынны ике улым белән кайтарып җибәрдем. Качырып эшләнде бу эш. Нәдер авылына — җизнисенә. Мәгъмүрә анда кайткач, мәктәпкә каравылчы булып эшкә керә. Олы улым 1 класска укырга кергән. Нәдергә мин дә елына ике мәртәбә — бер яз, бер көз кайтып йөри башладым. Бер ай торып килә идем. Аннан килгәч комендантка күренә идем, бер сүз дә әйтми иде.

Эшебез һаман шул дранка яру, түбә ябу. 1932, 1933 еллар шунда үтте. Иптәшләр дә иске. Мәгъмүрә бу вакыт колхозга кереп, мәктәптән бушаган чакларда колхозда да эшләп йөрде.

Мәктәптә алар ике каравылчы булып, эшләре бик тә күп икән. Бу вакыт мин Ютазыга, Казанга гаризалар язам. Мине дөрес раскулачивать итмәделәр дип, алты мәртәбә яздым. Тик берсенә дә җавап килмәде. 1934 елда язын Нәдергә, көзен Алматага кайтып кешеләргә эшләшеп йөрдем.

Нәдергә бер кайтуымда тагын гариза яздым, ТатЦИКның контроль комиссиясенә. Мине дөрес җибәрмәделәр, мин гаепсез дип. Бу гаризаны караганнар. Хәбәре Ютазы аша Алматага кайткан. Ул язуда мине «Акларга, высылкадан кайтарырга, ирек бирергә, кайда колхозга керергә теләсә шунда яшәсен», дип язылган диделәр.

Мин Нәдердән семьяны алып, Әлмәттән икебезгә дә паспортлар алып килдек Алма-



И. Надиров гаиләсе белән. 1971 ел.

тага. Исәп бар иде бөтен семья белән Ташкент ягына китәргә. Тик алай булып чыкмады.

Илбарыс Нәдердә укып калды, бажайларда торды, 5 класста иде инде, без Мәгъмүрә белән Әмир — өчебез Алматада Хәким абзыйларда вакытлыча урнашып яши башладык. Колхозга алдылар. Бу 1935 елның көзендә булды. Шул вакыт колхоз идарәсенә вербовщик килгән. Карелия лесхозына 4 ат, ике кеше җибәрергә кирәк дип. Бу эшне миңа куштылар. «Иптәш булса, барам», — дидем. Китәр көн җитте, иптәш юк, киттем бер үзем 4 ат белән. Ютазыга баргач, Кыска Елга авылыннан тагын 6 ат бирделәр. 10 ат белән киттем шулай Петрозаводскидан ары Пазежир дигән җиргә. Пазежирның үзендә леспромхоз дирекциясе, пекарня, кибеттә ни телисең бар. Монда бөтен эшче — фин халкы. Контордагы, кибетләрдәге халык бик чиста киенеп йөри. Финнәр усал халык. Тәкәббер, үзләре белән бер-ике кат сугышырга да туры килде. Ну, берне биреп икене алдык. Закир абзыйга күбрәк эләкте.

Апрельдә безне өйгә кайтырга була диделәр. Бәйрәкәдән Закир абзый белән үзебез алып барган атларны танып, табып алдык та, юлга чыктык. Петрозаводскига килеп, поездга утыртып җибәрделәр. Аннан Алматага кайттым. Апрельнең 15 иде. Чәчү вакыты. Председатель икенче кеше — Яркәев Сәлах. Аңардан өйне, усадьбаны сорыйм. Сәлах инде минем өйдә торучы Зиннәт Кәлимуллин белән дуслашып алган, өйне миңа кайтаруга каршы тора. Район хуҗалары аша сорарга куштылар. Бер көнне мине дә, Зиннәтне дә райисполкомга чакырдылар, тик анда да Яркәев сүзенә карап, миңа йортны бирмәскә дип, карар чыгардылар. Шулай итеп үзебезнең яр буендагы мунчага күчендек. 1937 елның языннан 1940 елга кадәр шул мунчада тордык. Бик гарьлек булса да, мәҗбүр булдык инде. Бер сыерыбыз, бер сарыгыбыз, ике кәҗәбез бар иде. 1937 елда икмәк бик нык уңды, кая куярга да түгел, 12 шәр кило бүлдек эш көненә. Үзебезнең мунча түбәсен, сарай түбәсен тутырдык... Бодай онының поты 5 сум, арыш оны 3 сум иде. Бер вакыт бер бричка он төяп Бөгелмәгә базарга барганым истә калган. Минем белән Илбарыс та барды. Әллә ничаклы кием-салым алып кайткан идем.

Алматада яшәгән чакта олы улыбыз Илбарыс 1942 елда Кәрәкәшле дигән авылда 10 класс бетерде. Аннары елдан артык Ютазыда эшләп йөрде. 1943 елда көзен Уфага авиация институтына укырга китсә дә, сугыш аркасында армиягә алынып 4 елдан артык шунда йөреп исән-сау авылга кайтты. Бераз вакыт үткәч Казанга китте укырга. 5 ел университетта укыды, аннары өч ел аспирант булды. 1956 ел көзеннән башлап бер институтта эшли. Хатыны Дания — укытучы. Ике бәбиләре бар: Зөлфия белән Илнур.

Икенче улым Әмир, 1931 елда туган, ул армиягә алынмады. 1956 елдан башлап Әлмәттә эшли, газосварщик булып. Хәзер Әлмәттә урын алып шунда йорт салырга уй-



И. Надиров туганнары һәм әнисе Мәгъмүрә белән. Әлмәт, 1970 ел.

лый.

Өченче улым Гамир, 1938 елгы. Әлеге көндә Әлмәттә укып йөри шоферлыкка. Укуы февральдә бетергә тиеш.

Дүртенче улым Наил дә Әлмәттә укый, 9 класста. Ул 1940 елда туган иде.

Без хәзерге вакытта Ютазы районының Алмата дигән авылында яшибез. 1957 ел мартыннан монда совхоз оешты. 1958 елда май ахырында Алматадагы өйне, бар вактояк әйберләрне сатып Әлмәткә килдек.

Рәхәтеннән михнәтен күбрәк күрдек шул
(Мәгъмүрә Шаһисламова хатирәләре)*

Мин әткәйдән 8 яшьләремдә калганмын. Әтием Хафиз исемле иде. Без өч кыз булганбыз. Өлкәне Фатыйма, уртанчыбыз Мөсәвәрә, кечесе — мин. Өйдә кызлар гына булганга күрә җир аз булган. Әткәйнең нибары җиде кисәк җире бар иде. Һәр кайсы өч-дүрт адымлык кына. Әүвәле душны ел саен өләшкәннәр, соңга таба өч елга бер генә кат бүлгәннәр. Әткәй өч ел буе рәнҗегән. Шуннан душ бүлгән елны гына вафат булган. 1908 елда ахры. Безгә әткәйдән бер өй, бер сыер калган. Әнкәем Гайнижамал иген чәчеп, киндер сугып көн күргән. Ул безнең өчебезне дә укытырга тырышкан. Остабикәгә имтихан биреп йөргән чаклар әле дә истә әле.

Фатыйма абыстай иргә бездән иртәрәк чыкты. Ә безне Мөсәвәрә абыстай белән икебезне дә 1918 елда бирде. Мөсәвәрә абыстайны Тайсуган авылына бирделәр, ә мине Нәдердәге йортыбызга керттеләр. Димләделәр дә эш бетте, мулла абзый никах укыды.

Әтиегез өйләнгәнче 9 ел читтә йөреп, кунакка гына дип кайткан була. Туганнары аны читкә яңадан җибәрмәскә сөйләшәләр. Агайлар моңа әйтәләр: «Давай, син кал Нәдердә, өйлән», — дип. Шуннан ул безгә йортка кергән инде. Әтиең нәселендә Надиров Арслан хаҗи булган, ягъни хаҗга барган бай кеше булып саналган. Аңа губернатор да килә торган була дип сөйлиләр иде. Ул Арсланның бер малае — хаҗи Мөхәммәт исемле була, аның малае Надиров Шамил әле дә исән, Габдрахман авылында председатель иде. Әтиең аның янына баргалап та йөрде без Әлмәткә кайткач.

1918 елның май числолары иде. Әтиең безнең өйгә килгәне истә әле дә. Өс-башында бик әйбәт киемнәр, җиңелчә зәңгәр пальтодан, кулында көкре таяк, бер бармагында алтын йөзек. Үзенчә бай инде. Бер янчык көмеш акча да алып килгән иде... Атаң и батыр булган инде, и кыланган инде, йөрәк тә булган үзендә, дәрт тә булган...

Өйләнгәч, ул бик ныклап эшкә кереште.

Безне авылдан 1931 елны җибәрделәр. Минем Әмир белән йөкле чагым иде. Әтиең белән Сабитов Хәйретдинне генә алып киттеләр бит. Әтиең җәй башында утын әзерләргә дип урманга киткән иде, аны шуннан алып киткәннәр, ә безне августа җибәрделәр. Алматада өч атыбыз, өч сыерыбыз калды, дөнья шул ул, дөнья, ул бер алдын, бер артын күрсәтә, диләр бит. Безне җибәргәнче әле бик каты тентү булганы истә тора. Ниндидер яшергән мал эзләделәр, берни дә тапмадылар. Әтиең үзенең тырышлыгы белән байый башлагач, көнчеләр, дошманнар күбәйде. Ул бит урамда таштан кибет тә эшләткән иде.

Ярар, безне Алматадан Бөгелмәгә китерделәр. Монастырь дигән таш йортка яптылар. Бу инде төрмә иде. Мин олы корсаклы, сиңа 5 яшь иде. Шул кызыл таш төрмәдә 9 көн яттык. Хәйретдин абзыйны кире кайтарып җибәрделәр. Авылдан бер безне генә сөрделәр.

Безне Бөгелмәгә озатканда әбиеңне Нәдердән килгән Сабир җизни алып калды, ышаныч язуы белән. Кызыл таш төрмәдән чыккач, безне вагоннарга төяп Магнитстрой-Златоуст ягына җибәрделәр. Уржумка дигән стансага барып төштек. Халыкның чуты-кырые юк. Атаң анда урман эшендә булды, аны бригадир иттеләр. Ә без кара урман эчендәге бараста тордык. Әтиеңнең башына бүрәнә төшеп, башын ярды. Шуннан бирле гомере буена башы авыртты.

Без торган баракның өстендә тавыклар, астында сарыклар иде. Барак 33 кешелек

* Хатирәләр кыскартып бирелә.

иде. Моржа чыгарып тордык инде шунда. Магниторскидан 40 чакрым диләр иде. Әмир шул бараста туды, көзен. И, елан күп иде анда, кара еланнар мәш килә иде. Барак янында агым су бар, син шул тирәдә уйнарга ярата идең. Бик шаян, шук малай идең, тирә-күрше хәйран була иде.

1932 елның җәенә таба без өч хатын, алты бала качтык аннан. Качтык дип, безне Камы кешесе Гариф Уфага кадәр илтеп, поездга утыртып җибәрде. Ул Гарифның хатыны Сажидә, тагын бер хатын Мәсрүрә исемле иде. Аларның да икешәр бала. Кайтып төштек Бөгелмәгә. Аннан мин Нәдергә, алар Камыга юл тоттык. Ахырдан ишетүемчә, аларны Котдус исемле туганнары этап белән кире җибәртә.

Юлда Әмирне яулык белән аркама асып, сине җитәкләп барганым әле дә истә. Нәдердә авыл халкы миңа якты чырай күрсәтте. Фатыйма абыстайларда яши башладык. Атаңнан хатлар килгәләп торды. Әгәр кире җибәрсәләр, без фәлән урманда, шуннан эзләп табарсыз, дип яза иде.

Колхозга керсәм, мине кире җибәрмәсләр дигәч, колхозга керү артыннан йөри башладым. Сельсоветта әйттеләр, иреңнән аерылсаң гына колхозга алабыз диделәр. Аерылдым. Ике бала белән ничек итеп кара урман арасына кабат китим инде. Бер әшәке Гариф исемле кеше бар иде. «Кулак хатыны килгән икән, шуңа күрә колхозның эшләре алга бармый», — дип сөйләнеп йөргән бу. Андый денсезләр бар иде инде ул вакытларда. Ул Гарифның ахырдан ике аягын кистеләр, рәхим күрмәде. Колхозга керсәм дә, төп эшем мәктәптә булды. Аена 1 сум 80 тиен түлиләр иде. Без икәү сторожиха булып эшләдек. Тугызар бүлмә иде һәркайсыбызга. Ул вакытта мәктәптә 700 ләп укучы, 18 укытучы бар дип сөйлиләр иде. Зәй буенда мәктәпнең үз басуы бар иде. Анда иген чәчәләр. Мәктәпнең үзендә столовые бар иде. Әй, гомерләр. Тамак өчен йөрдек инде ул вакытларда. Мәктәптә атна саен йә театр уйныйлар, йә кино күрсәтәләр. Ул вакыт тавышсыз кино иде, электр белән эшләми, кул белән әйләндерә торган.

Бер вакыт мәктәп директоры Шагалиев чакыра мине: «Әйдә, Мәгъмүрә, театр карыйбыз», — ди. Ул арада сәхнәгә артистлар чыгалар. Берсе ак алъяпкычтан, башына кызыл косынка бәйләгән. Кулында Әлифба китабы. Латин хәрефләре белән. Бу шуннан укый нәрсәдер. Икенчесе башына борынгыча итеп иске яулык бәйләгән, өстенә камзул кигән. Кулында искечә язылган бер китап, шуннан нидер укыган була. Бусы, янәсе мин инде, имеш, мин яңача укый белмим, искелек ягында калган кеше. «Ай, мәктәптән әйбер урлаган бу, дип рисвай итмәгәч, бусына бик исем китми», — дидем дә чыгып киттем. Көлешеп калдылар.

Алматада, бигрәк тә сугыш елларында, интегеп яшәргә туры килде. Ачлык, икмәк юк. Хатын-кыз да, бала-чага гына эшләп маташа. Кеше башына 15 әр гектар җыярга бирәләр иде. Шунда эшли-эшли билләрем бөкрәйде. Шул атаң тырышлыгы аркасында ач булмадык, аллага шөкер.

Фотолар авторның шәхси архивыннан.

РЕЗЮМЕ

И. Надиров предлагает вниманию читателей воспоминания семьи Нурислама и Магмуры Шагисламовых, выходцев из д. Ново-Надырово Альметьевского района РТ. Воспоминания, изложенные в форме автобиографии Н. Шагисламова, одухотворены личными переживаниями, деталями крестьянского быта, неизбывной тоской по родным местам и суровой правдой нелегкой жизни тех времен.